РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы Лермонтов урамы, 2 йорт

тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.02.2018 № 6-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты
тарафыннан 2014 нче елның 20 нче январендә
кабул ителгән 3-п номерлы «Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл
җирлегендә муниципаль торак контроле үткәргәндә
административ регламентны раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасы протесты һәм «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 нче елның 31 декабрендә кабул ителгән 485-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба районы Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2014 нче елның 20 нче январендә кабул ителгән 3-п номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә муниципаль торак контроле үткәргәндә административ регламентны раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлегендә муниципаль торак контроле үткәргәндә административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр

кертергә:

1.1. 3.1. пунктын тубәндәге редакциядә бәян итергә:

«3.1. Планнан тыш тикшерүгә нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне якимәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган күрсәтмәне юридик зат, шәхси эшмәкәр белән үтәү вакыты үтү;

2) юридик затларга, шәхси эшмәкәргә хокукый статус, махсус рөхсәт кыягазе, рөхсәт бирү кагыйдәре белән бәйле булган очракта, муниципаль контроль органына юридик заттан яки шәхси эшмәкәрдән хокукый статус бирү турында, аерым төр эшчәнлеккә махсус рөхсәт кыягазе (лицензия) һәм башка юридик әһәмияткә ия булган гамәлләр башкару өчен рөхсәт турында гариза керү;

3) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән хезмәттәшлексез контроль буенча чараларга анализ ясау нигезендә муниципаль контроль органнарында вазифа башкаручы затлар тарафыннан дәлилләнгән гариза керү, гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән кергән гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр буенча алдан тикшерү, массакүләм мәгълүмәт чараларыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан кергән түбәндәге фактлар турында мәгълүмат:

а) гражданнарның сәламәтлегенә, тормышына куркыныч тудыру, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясенең мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрләргә), Россия Федерациясе Музей фондына кертелгән музей предметларынаһәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондындагы аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларга,милли китапханә фондысоставына керүчеаерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгару куркынычы;

б) гражданнарның сәламәтлегенә, тормышына зыян салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясенең мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрләргә), Россия Федерациясе Музей

фондына кертелгән музей предметларынаһәм музей коллекцияләренә, Россия Федерациясе Архив фондындагы аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларга,милли китапханә фондысоставына керүчеаерым тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт куркынычсызлыгына зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгару;

в) кулланучылар хокукларын бозу (кулланучылар хокукларын яклау буенча федераль күзәтчелек органнарына мөрәҗәгать иткән очракта, хокуклары бозылган гражданнар юридик затка яки шәхси эшмәкәрләргә үз хокукларын яклау өчен мөрәҗәгать итеп, әлеге юридик зат яки шәхси эшмәкәр гаризаны карамаган очракта);

4) күрсәтелгән Федераль законның 8.1. статьясының 1 нче һәм 2 нче өлешендәге күрсәтелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән хезмәттәшлексез дәүләт контроле (күзәтчелеге) вакытында юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлек параметрларын ачыклау, әлеге параметрларга туры килү-килмәве планнннан тыш тикшерү үткәрү өчен куркынычлык индикаторы булып тора;

5) Россия Федерациясе Президентыйөкләгән бурычлар һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында үткәрелгән прокурор таләпләре нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрү турында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан чыгарылган боерык;

6) дәүләт күзәтчелек органнарына, муниципаль торак контроле органнарына гражданнардан, шул исәптән юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү, аерым алганда, система аркылы,дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле узидарә органнарыннан кергән мәгълүмат, күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда яшәүче милекчеләргә һәм файдаланучыларгакоммуналь хезмәтләр күрсәтүталәпләрен, бирү, бирүне туктатып тору һәм чикләүкагыйдәләрен, торак-милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслашкан кулланучылар кооперативыбулдырутәртибеталәпләрен, торак-милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслашкан кулланучылар кооперативы уставын һәм мондый ширкәт яки мондый кооператив

уставына үзгәрешләр кертү тәртибенә, күпфатирлы йортбелән идарә итү өчен идарәче оешма белән килешү төзү максатларында юридик затка бәйсез рәвештә, оештыру-хокукый формалары яки шәхси эшмәкәр эшчәнлек алып баручы идарә итү буенча оешма (алга таба - идарәче оешма) сайлап алу тәртибен, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнекарап тоту һәм ремонтлаубуенчаидарәче оешма беләншартнамә төзү турында карарны, Россия Федерациясе Торак Кодексының 164 нче статьясының 1 нче өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнекарап тоту һәм (яки) ремонтлаубуенча эшләр башкару буенча шартнамә төзү турында карарны,

әлеге килешүшартларын һәм аларны төзүне раслау тәртибен, күпфатирлы йорттагомуми мөлкәтне, бина милекчеләренең мөлкәтен карап тоту, агымдагы һәм гомуми милекне капиталь төзекләндерү тәртибенбозу фактлары турында, Россия Федерациясе Торак Кодексының 162 нче статьясының 2 нче өлешендә каралган идарәче оешмаларга йөкләнгән йөкләмәләрне бозу фактлары, гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү индексларның чикләрен бозу фактлары, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр күрсәтү)куллану нормативлары күләмен нигезсез билгеләүфактлары, коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр күрсәтү)нормативлары составы таләпләрен бозу,коммуналь ресурслар (коммуналь хезмәтләр күрсәтү)куллануnормативларыалымнарын билгеләү шартларын сакламау, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнетоту кагыйдәләрен һәм түләү күләменүзгәртү кагыйдәләрен бозу, социаль файдалану йортларында яшәүче яллаучылар тарафыннан әлеге йортларда тору кагыйдәләрен бозу, социаль файдалану йортларында торучылар белән найм килешүләре төзү һәм үтәү тәртибен бозу, җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлек алып баручызатлар, гражданнар тарафыннан системадамәгълүматурнаштыруталәпләрен бозу фактлары турында дәүләт торак күзәтчелеге органы һәм муниципаль торак контролеорганы тарафыннаначыкланган мәгълүмат.

Муниципаль торак контроле органы белән (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнары җирле үзидарә органнарының аерым дәүләт

вәкаләтләрен бирү үткәрү буенча очракларда вәкаләтләр бирелгән очракта, тикшерүләр гамәлгә ашырганда лицензия контроле) планнан тыш тикшерүгә нигез булып Россия Федерациясебаш дәүләт торак инспекторының Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтененңйөкләгән бурычлар нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерүтурында боерыгы (күрсәтмәсе) тора.

Күрсәтелгән нигезләр буенча прокуратура органнары белән килешмичә һәм тикшереләсе оешмага алдан хәбәр итмичә үткәрелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев